БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 март 2026 ел № 44

**Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17 (1) статьяларына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 26 февралендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Балтач район Советы **карар кабул итте:**

1.Балтач район Советының 2014 елның 22 октябрендәге 250 номерлы карары (2015 елның 17 апрелендәге 273номерлы, 2015 елның 16 июлендәге 287 номерлы, 2023 елның 23 мартындагы 175 номерлы, 2025 елның 10 ноябрендәге 19 номерлы үзгәрешләр) белән расланган Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмәдә тапшыру тәртибе билгеләнә:

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан. Күрсәтелгән

белешмәләр «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне (алга таба – керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла;

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон) каралган чыгымнар турында Балтач муниципаль районының тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм формада.

1.2. Нигезләмәнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Вазыйфалар исемлегендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфаларын біләп торучы муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган белешмә формасы буенча ел саен хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматлар тапшырыла.».

1.3. Нигезләмәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. «Дәүләт вазыйфаларын біләп торучы затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Дәүләт вазыйфаларын біләп торучы затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль закон) белән каралган чыгымнар турындагы мәгълүматларны тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәткәр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый мәгълүматларны тапшыру өчен билгеләнгән тәртип һәм форма буенча тапшыра.

1.4. Нигезләмәнең 13 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль район Башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р. Р. Нотфуллин